| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 1 марты №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 16 октябрендәге 35 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (15.10.2018 ел, № 30, 29.11.2018 ел, № 38 үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезләмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 16 октябрендәге 35 номерлы карарына (15.10.2018 ел, № 30, 29.11.2018 ел, № 38 үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карарның 2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 0,1 процентка карата:

- гараж һәм машина урыны;

- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган салым салу объектларында, шул исәптән исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары;».

2.Әлеге карарны Яңа Чыршылы поселогы, Заречная урамы 25, Үзәк урамы, 12а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Ә.Мөхәмәтшина